ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2026 Олы Кайбыч ав. № 225

Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 25 декабрендәге 1682 номерлы «Татарстан Республикасында, шул исәптән социаль контракт нигезендә, дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында» карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә;

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы.

3. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 577 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтъ белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары О.Д. Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А. Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026елның «15» 05
225 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА СОЦИАЛЬ КОНТРАКТ НИГЕЗЕНДӘ ДӘҮЛӘТ СОЦИАЛЬ ЯРДӘМЕ КҮРСӘТҮ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ КАРАУ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Дәүләт социаль ярдәмен социаль контракт нигезендә күрсәтү мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба — ведомствоара комиссия), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 25 декабреннән 1682 номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» карарын тормышка ашыру максатында, авыр тормыш хәлендә калган гражданнарның үтенечләрен һәрьяклы һәм объектив карау, гражданның һәм (яки) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгу буенча килештерелгән чаралар эшләп чыгару өчен оештырыла һәм коллегиаль орган булып тора.

2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының, шулай ук Кайбыч муниципаль районының муниципаль хокукый актлары, шулай ук әлеге нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Ведомствоара комиссияне рәис җитәкли.

Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре, шул исәптән территория үсеше бүлеге, опека һәм попечительлек бүлеге, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, эш белән тәэмин итү хезмәте, җирле социаль яклау органы, җирле үзидарә органы вәкилләре, социаль контракт төзүне раслау (расламау) турында бердәм фикер чыгару, социаль адаптация программасы һәм аңа куелган материаллар, шулай ук тәкъдим ителүче тапшыручы тарафыннан әзерләнгән бизнес-план (чыгымнар сметасы) яки күрсәтелгән документларны эшкәртү кирәклеге турында килештерелгән фикер булдыру максатында Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан башка органнар һәм оешмалар вәкилләре керә.

4. Ведомствоара комиссия дәүләт социаль ярдәмен социаль контракт нигезендә күрсәтү мәсьәләләрен социаль контракт төзелгәнче карый, тәкъдим ителгән документларга бәя бирә, кирәк булганда социаль адаптация программасын һәм (яки) бизнес-план эшкәртү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр кертә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин түгеллеге) турында бәяләмә әзерли.

5. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

авыр тормыш хәлендә калган затларга законнар нигезендә адреслы социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасында федераль башкарма власть органнарының территория органнары, республика башкарва власть органнарының территория органнары, Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм Кайбыч муниципаль районының муниципаль

учреждениеләре, Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан башка оешмалар белән үзара эшләтүне тәэмин итү;

гражданин тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләр нигезендә гражданның һәм (яки) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгуы өчен шартлар тудыру.

6. Ведомствоара комиссия түбәндәге бурычларны хәл итү хокукына ия:

ведомствоара комиссия эшенә катнашу өчен Татарстан Республикасында федераль башкарма власть органнарының территория органнары, республика башкарма власть органнарының территория органнары хезмәткәрләре һәм белгечләрен, шулай ук Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар вәкилләрен җәлеп итү;

Татарстан Республикасында федераль башкарма власть органнарының территория органнарыннан, республика башкарма власть органнарыннан һәм аларның территория органнарыннан, оешмалардан һәм хезмәткәрләрдән билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүматлар сорау һәм алу;

авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны ведомствоара комиссия утырышына чакыру, аларның аңлатмаларын тыңлау;

гражданның һәм (яки) гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгуга юнәлтелгән, социаль адаптация программасында ныгытылган чараларны кануннар һәм бюджет йөкләмәләре чикләре эчендә гражданнар белән фикер алышу һәм тәкъдим итү;

гражданның һәм (яки) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгу буенча чаралар үткәрүне Татарстан Республикасында федераль башкарма власть органнарының территория органнарына, республика башкарма власть органнарының территория органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә, Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан башка оешмаларга, аларның вәкаләтләре чикләрендә тәкъдим итү;

законнар нигезендә социаль адаптация программасында беркетелгән шартларның һәм йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүне билгеләү.

7. Ведомствоара комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа куелган материалларны, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан әзерләнгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) ведомствоара комиссия утырышында карау;

социаль контрактка, социаль адаптация программасына, шул исәптән анда күрсәтелгән чаралар составына, һәм (яки) аңа куелган материалларга, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан әзерләнгән бизнес-планнга (чыгымнар сметасына) карата искәрмәләрне территория социаль яклау органына тәкъдим итү;

эшкәртелгән социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа куелган материалларны, шулай ук тәкъдим ителүче тапшыручы тарафыннан әзерләнгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) кабаттан карау;

социаль контракт төзүне, социаль адаптация программасын һәм аңа куелган материалларны, мөрәҗәгать итүче тарафыннаn әзерләнгән бизнес-планны (чыгымнар сметасын) раслау (растламый) турында бердәм фикер чыгару яки күрсәтелгән документларны эшкәртү кирәклеге турында килештерелгән фикер булдыру.

8. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген аның рәисе җитәкли, ул булмаганда — ведомствоара комиссия рәисе урынбасары.

9. Ведомствоара комиссия утырышлары аның рәисе тарафыннан расланган утырышлар графигы буенча үткәрелә.

10. Ведомствоара комиссия утырышлары, аларда билгеләнгән ведомствоара комиссия әгъзалары составының яртысыннан ким булмаган катнашучылар булганда, хокуклы була.

11. Ведомствоара комиссиянең һәр утырышы алдыннан тулы хокуклы булуын билгеләү өчен ведомствоара комиссия әгъзаларын теркәү уздырыла.

12. Ведомствоара комиссия карарлары ведомствоара комиссиянең катнашучы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара комиссия утырышында рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора.

Ведомствоара комиссия әгъзалары тавыш бирүне шәхсән үзләре үтиләр, үз вәкаләтләрен башка затларга тапшыру рөхсәт ителми.

13. Ведомствоара комиссия тәкъдим ителгән документларны бәяли, кирәк булганда, социаль адаптация программасы һәм (яки) бизнес-план эшкәртү буенча тәкъдимнәр һәм үтенечләр кертә, социаль контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин түгеллеге) турында игълан бирә.

Ведомствоара комиссия бизнес-планны карау һәм бәяләүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 25 декабре 1682 номерлы «Татарстан Республикасында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү тәртибе турында» карары (алга таба — бәяләү бите) белән расланган Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү тәртибе турында нигезләмәнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән форма һәм критерийлар буенча башкара. Ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан һәр критерий бәяләү битенә туры китереп бәяләнә.

Һәр критерий буенча ведомствоара комиссия әгъзасы аңлатма бирә. Бәяләү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия рәисе бизнес-плана гомуми аңлатма бирә, анда бизнес-план эшкәртү һәм (яки) үзгәртү буенча үтенечләр, бизнес-план раслаудан баш тартуның нигезләнгән сәбәпләре күрсәтелщ. Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда, гомуми аңлатманы ведомствоара комиссия рәисе урынбасары бирә.

Бизнес-план бәяләү нәтиҗәләре бәяләү бите нигезендә чыгарыла һәм ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

14. Ведомствоара комиссия утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карап, түбәндәгеләр турында карар кабул итә:

социаль адаптация программасы һәм (яки) бизнес-планны раслау һәм мөрәҗәгать итүче белән социаль контракт төзүне тәкъдим итү турында;

социаль адаптация программасы һәм бизнес-план проектына үзгәрешләр кертү тәкъдиме турында (конкрет тәкъдимнәр күрсәтелә);

сайланган эшчәнлек төренең икътисадый нәтиҗәсезлеге сәбәпле социаль адаптация программасын гамәлгә ашыруның һәм мөрәҗәгать итүче белән социаль контрактны (мондый карарны кабул итүнең мотивлаштырылган нигезләмәсе белән) гамәлгә ашыруның максатка ярашсызлыгы турында;

Ведомствоара комиссия социаль контрактны, социаль адаптация программасын һәм аңа куелган материалларны, шулай ук бизнес-планны (чыгымнар сметасын) раслаудан баш тарту карарын кабул итә ала.

15. Ведомствоара комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышында рәислек итүче зат һәм ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026елның «15» 05
225 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Макарова О.Д. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары - **Комиссия рәисе** |
| Тимершина С.Б. | Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы - **Комиссия рәисе урынбасары** (килешү буенча) |
| Фәсхетдинова Л.В. | Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы “Өмет” халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге бүлеге мөдире - **комиссия сәркатибе** (килешү буенча) |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Камалеева Р.Р. | Кайбыч районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Камалеева Э.Р. | Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге Дәүләт казна учреждениесенең Кайбыч районы буенча бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| Камалетдинов Р. М. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Ильясова И.Ф. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Гарафетдинова З.Р. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |
| Нигъмәтҗанова Г.Н. | Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы “Өмет” халыкка социаль хезмәт |

| | |
|---|---|
| | күрсәтү комплекслы үзәге директоры (килешү буенча) |
| Лотфуллина Р.Г. | Кайбыч муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча); |
| Шәрәфиева Р.Р. | «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча Кайбыч районындагы филиалы социаль координаторы (килешү буенча) |
| Тараканов П.П. | Мәлки авыл җирлеге кулланучылар җәмгыяте рәисе (килешү буенча) |